ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.17,
с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 17йорт,
Акбаш авылы, 423958

Тел.:(85593) 4-14-34, факс:4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 14** **«04» октябрь 2023 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2012 елның 25 июнендәге 16 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты карарында гражданнарның һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының үз көчен югалтуын тану турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2006 елның 02 маендагы «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»гы 59-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» федераль закон, 2023 елның 26 гыйнварында «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында»гы 1-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2003 елның 12 маендагы «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында»гы 16-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2012 елның 25 июнендәге 16 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты карарында гражданнарның һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты
җитәкчесе вазифасын башкаручы И.Р.Сәхибуллина